ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 71 от «19» 02 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү мәсьәләләре буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге №ФЗ-209 Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы ТРЗ-7 нче санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Мамадыш муниципаль районы территориясендә эшмәкәрлек эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итү максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 июнендәге 775 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү мәсьәләләре буенча Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- түбәндәге эчтәлекле 4.6 пункт өстәргә:

Иҗтимагый совет рәисе Совет белән уртак җитәкчелек итә, Советның эш юнәлешләрен һәм планын билгели, раслый, комиссия утырышлары беркетмәләрен, беркетмәләрдән өземтәләрне, Совет кабул иткән карарларны раслый, Совет кабул иткән карарларның үтәлешен контрольдә тота.

Иҗтимагый совет секретаре Совет эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра, Советның эш башкаруын алып бара, совет әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга үткәрелү көненең датасы, урыны һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, фикер алышуга тиешле документлар проектларын һәм башка материалларны җибәрә, Совет утырышларын әзерләүне оештыра.

- 5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Иҗтимагый совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Совет карары совет әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавышы

0000010776

хәлиткеч булып тора. Совет утырышында кабул ителә торган карарлар утырышта рәислек итүче һәм секретарь кул куйган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Совет утырышлары беркетмәләренең күчермәләре Совет утырышы уздырылганнан соң 3 эш көне эчендә аның әгъзаларына җибәрелә.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче — И.М.Дәрҗеманов